

Роспотребнадзорнын РМ буенча мәгълvматлары буенча, Мордовиядә кискен респиратор вирус инфекцияләре белән авыручылар санынын сезонлы кvтәрелvе билгеләнә.
Узган атнада республика террито-риясендә 6785 ОРВИ очрагы теркәлгән, бу узган атнадагы авыру дәрәҗәсеннән 22,3% ка югарырак. Халыкнын авыруы башлыча негриппоз этиологияле респиратор вируслар һәм COVID-19 циркуляциясе белән бәйле. Авырулардан кvпчелек очракта COVID-19, аденовируслар, риновируслар, парагрипп вируслары, бокавируслар һәм башкалар. Республикада грипптан барлык финанслау чыганаклары хисабына 395 меннән артык кеше прививка ясаган, бу республика халкынын 51,2 процентын тәшкил итә. Үз чиратында, тобәктә коронавирус белән авыручылар саны буенча хәл тотрыклылана, ә узган атнада анын ике ай эчендә беренче тапкыр 11,7% ка кимvе билгеләнгән.
Топ симптомнары турында докторлар болай ди. Грипп, коронавирус һәм ОРВИ билгеләре, чыннан да, бик охшаш, шуна кvрә диагноз куйганда хаталанырга да момкиннәр. Әмма бу авыруларнын һәрберсенен vз vзенчәлекләре бар. Мәсәлән, грипп белән ешрак козен һәм кышын чир-лиләр. Ул кинәт башлана: температура кискен кvтәрелә, калтырата, тән сызлый, баш авырта, яктылыктан курку барлыкка килә, тамак авырта һәм тавыш бетә, каты ютәл башлана.
Кискен респиратор вируслы инфек-цияләр ел әйләнәсенә очрый. Аларнын берничә торе бар. Парагрипп - акрынлап башлана, температура артык кvтәрелми, тамак авырта, тавыш бетә, ютәлләтә. Риновирус инфекциясе - кискен башлана, борын тыгыла, борын белән сулыш алу авырая, исне һәм тәмне сизv кими, температура нык кvтәрелми. Аденовирус инфекциясе - кискен башлана, температура югары яки уртача була, тамак авырта, юеш ютәл, коньюнктивит кvзәтелә. Респиратор-синцитиаль инфекция - бетми торган коры ютәл җәфалый. Бу ин таралган инфекцияләр, алар кvпкә кvбрәк, әлбәттә. Һәркайсы аерым дәвалау ысулын таләп итә.
Ковид-19 коронавирус инфекциясе - тән температурасы артык кvтәрелми, аз гына юеш ютәл, тын бетv, тиз ару, кvкрәк читлеген нидер баскан кебек тою, исне һәм тәмне югалту, азрак тамак авырту кvзәтелә. Авырунын 6-8 коненә тын алу нык авырлаша.
Теләсә кайсы очракта, авырунын беренче билгеләре булганда ук я терапевтка, я педиатрга морәҗәгать итәргә кирәк! Ин моһиме, эшкә йормәгез, баланы балалар бакчасына яки мәктәпкә илтмәгез. Һәрхәлдә, клиник диагноз билгеләнгәнгә кадәр. Беренчедән, авыруны аякта vткәрv организм очен икеләтә куркыныч, икенчедән, болай сез эштә коллегаларыгызга чир йоктырмаячаксыз.
Сак булыгыз, исән булыгыз!
Н.ХӘЛИЛ әзерләде